**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**Урсаевского сельского поселения**
**Азнакаевского муниципального**
**района**

ул. Центральная, д. 60, село Урсаево,
Азнакаевского муниципального района, 423318
Тел. (факс) (8-85592) 35-0-36

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай муниципаль районы**
**Урсай авыл**
**җирлеге Советы**
**БАШЛЫГЫ**

Үзәк урам, 60, Урсай авылы
Азнакай муниципаль районы, 423318
Тел. (факс) (8-85592) 35-0-36

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от «16» ноября 2021г. № 6

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлегенең Урсай торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Уставы белән, **карар чыгарам:**

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Урсай авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2021нче елның 27 нче ноябрендә 09 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә: Үзәк, Совет, Кошевой, Куйбышев, Киров, Тукай, Гастелло урамнары,

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Урсай авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2021нче елның 27 нче ноябрендә 13 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын билгеләргә:Ленин, Җәлил, Горький,Космодемьянская, Төзүчеләр урамнары

3.Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Урсай авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- гражданнар җыенының беренче этабын уздыру вакыты – 27 нче ноябрь 2021 нче ел 09.00 сәг.тән 10.00 сәг.кадәр;
- гражданнар җыенының икенче этабын уздыру вакыты – 27нче ноябрь 2021 нче ел 13.00 сәг.тән 14.00 сәг.кадәр;
- гражданнар җыенының беренче һәм икенче этабын уздыру урыны – Урсай авылы, Совет ур. , 14 нче йорт, Урсай авыл мәдәният йорты янында;

4. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2021 нче елның 16 нче ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Урсай авылы, Үзәк урамы, 60 нчы йорт

- сайлау хокукына ия булган Урсай торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләү;

- Урсай торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнарның җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2022 нче елда Урсай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 нче Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, кендезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә, 2 нче төркем инвалидлардан түләүне киметеп, аны 250 сум күләмендә билгеләп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

-Урсай авылында бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү («Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр кене», «Инвалидлар декадасы», «Яңа ел»,);

- Урсай авылы территориясен төзеклəндерүне оештыру (тракторчыга карны механикалаштырып җыю, юлларны кардан чистарту буенча чит оешмалар хезмәтләре өчен түләү);

- җирлек территориясен тезеклəндерүне оештыру (мәчет, авыл клубы, ФАП һәм балалар бакчасы территориясе), территорияне механикалаштырылган чабу буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, килешү буенча эшләр, ягулык-майлау материаллары һәм триммер өчен запас частьлар сатып алу, территорияне санитар чистарту буенча хезмәт күрсәтүләр, территорияләрне яшелләндерү буенча чаралар, Мафлар сатып алу һәм урнаштыру. Урсай авылының Ленин, Җәлил, Горький, Космодемьянская, Киров, Кошевой, Гастелло,Куйбышев,Үзәк урамнары ечен исемнәре язылган күрсәткечләр сатып алу, әзерләү,урнаштыру.

- халыкны су белән тәэмин итүне оештыру (су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау һәм карап тоту, килешү буенча эшләр өчен түләү, материаллар, җиһазлар сатып алу, авария хәлләрен бетерү, торбаларны алыштыру, ЗСО чыганакларын тезеклəндерү, ЗСО проектларын әзерләү буенча хезмәтләр ечен түләү, Урсай авылында эчә торган суны биохимик һәм бактериологик анализлау үткәрү);

- Урсай авылында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту (юлларга вак таш җәю, таш салу, вак таш җәю, Урсай авылында Куйбышев, Киров урамнарына , төзелгән килешү буенча түләү);

- Урсай авылында балалар уен мәйданчыгын сатып алу һәм урнаштыру

- Урсай авылында урамнарны яктырту (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү

« РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Урсай авылы, Үзәк ур., 60 нчы йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

7. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Башлык: З.Х.Рахимьянова